Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
«Юлсубино  авыл җирлеге» составына керүче Юлсубино авылы    торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ**

2024елның  22ноябре                                                    № 4

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2025елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль "Юлсубино авыл җирлеге" составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан гайре 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

1. Урам утларын урнаштыру  һәм ремонтлау;
2. Су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;
3. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын(чишмәләрне)төзекләндерү;
4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
6. Торак пункт территориясен төзекләндерү;
7. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.
8. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
9. Ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче,
Юлсубино  авыл җирлеге  башлыгы                                        Х.Х.Гатиятов